**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы
**КАРАРы**

2023 елның 07 июне № 27 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 17.02.2021 № 30 карары белән расланган
Татарстан Республикасы Ютазы район Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый проектларга коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»13.07.2018 № 55-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында "31.12.2022 № 109-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2021 елның 17 февралендәге 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы район Советы регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 13 статьясы 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район Башлыгын сайлау район Советы депутатлары тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән район халкының, иҗтимагый берләшмәләрнең, Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы

Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин